ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.12.2019 г. Заинск № 652

**"Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында" 2018 елның 06 мартындагы 360 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45нче маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында" 2018 елның 6 мартындагы 360 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 июлендәге 1186 номерлы, 2009 елның 19 февралендәге 58 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1 1.2.пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «административ регламент - дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен һәм дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын билгели торган норматив хокукый акт;".

2. Карарны Татарстан Республикасының pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары М.И. Захаровага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**